**СОВЕТ КУРКАЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район, п.ж.д.рзд. Куркачи, ул. Гагарина, 7

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОРКАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык тимер юл разъезды бистәсе, Гагарин урамы, 7

тел./факс 8(84365) 71-2-15, e-mail:Kurk.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**21 сентябрь 2020 ел** **№ 1**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан Муниципаль берәмлек башлыгын сайлау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 9 пункты, 44 статьясындагы 2 өлеше нигезендә һәм хисап комиссиясенең 2020 елның 21 " сентябрендәге 2 номерлы беркетмәсе нигезендә, Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгын сайлау буенча яшерен тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга һәм 5 нче Коркачык бермандатлы сайлау округы депутаты, Коркачык авыл җирлеге башлыгы һәм Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советы рәисе итеп Салихҗанов Ранис Фәнис улын сайларга.
2. Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советы муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына керешү көне итеп, аны Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан сайланган көн дип санарга.
3. «Җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 1 өлеше һәм Коркачык авыл җирлеге Уставының 43 статьясындагы 5 нче өлеше нигезендә Салихҗанов Ранис Фәнис улын Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе итеп билгеләп куерга.
4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Утырышта рәислек итүче
Коркачык вәкиллекле органы
8 нче номерлы сайлау округы депутаты Р.Ш. Зәйнуллин